**ТУКАЙ ШӘХЕСЕН ҺӘМ ИҖАТЫН ТӨШЕНҮ ЮЛЫНДА**
**(тәгъзияләр мисалында)**

Соңгы елларда җәмгыятебездә барган кискен иҗтимагый-сәяси, рухи-мәдәни үзгәрешләр әдәби мирасны барлау, моңа кадәр бәяләнгән әдәби күренешләргә яңача карау, хакимлек иткән марксистик-ленинчыл идеология кысаларына туры килмәү сәбәпле өйрәнелми яткан рухи байлыкны укучы җиткерү өчен, киң мөмкинлекләр ачты. Октябрь инкыйлабыннан соң, илдә урнашкан вәзгыять белән килешмичә, мөһаҗирлеккә китәргә мәҗбүр булган С. Максуди, Г. Терегулов, Г.Исхакый һ. б. лар мирасына гына түгел, ә исеме һәм шигырьләре телебездән төшми торган сөекле шагыйребез Габдулла Тукай белән бәйләнешле күп кенә материалларга да табу салына. Г.Тукай тормышын һәм шигърияти гомуммилли яссылыкта бәяләгән, аның фани дөньяда яшәешен, шигъри сәләтен, вакытсыз үлемен дини-фәлсәфи, Ислам мәдәнияте кануннарына салып үлчәгән тәгъзия-мәкаләләр, язмалар укучыларга җиткерелми. Мондый эчтәлектәге язмаларда Тукай шәхесен аңлау һәм бәяләү юллары, үлчәүләре һәм авторлар позициясе махсус өйрәнелүгә лаек. Бу юнәлештә Тукай фәнендә шактый зур нәтиҗәләргә ирешелгән һәм шул ук вакытта фикер-караш төрлелеген дә ассызыкларга кирәк.

Мәгълүм булганча, Г.Тукайның вакытсыз үлеме татар һәм төрки-мөселман дөньясында киң яңгыраш ала һәм бу вакыйга мөнәсәбәте белән язылган язмалар 1913-1914 еллар вакытлы мабугатында, бигрәк тә “Йолдыз”, “Вакыт”, “Кояш”, “Ил”, “Мәктәп”, “Аң” газета-журналлары битләрендә яктыртыла. “Тукаев, вафат иткәннән соң, матбугатны бик җитди рәвештә мәшгуль итте. Аның шигырьләре, шагыйрьлеге хакында төрле фикерләр, мөляхәзәләр йөртелде. Хәяте хосусияте хакында иптәшләре, белеш-танышлары тарафыннан күп хатирәләр язылды. Төрле җенес, төрле сыйныфтан булган кешеләр аңа булган мәхәббәт вә мәфтүниятләрен (сокландуларын) аның үлеме илә хасыйль булган кайгыларын, моң вә зарларын изһар итеп (күрсәтеп), тәэссефләр (кайгы), тәгъзияләр, мәрсияләр... яздылар”[2:53-54] – дип күрсәтә Җ.Вәлиди.

Дөрес, Тукай исемен, иҗатын зурлап һәм вакытсыз вафатына ачынып, кайгырып язылган мәкаләләрнең, тәгъзияләрнең, телеграммаларның күпләп вакытлы матбугат битләрендә басылуы төрле катлам кешеләре, аерым шәхесләр тарафыннан бертөрле генә кабул ителми. Мәсәлән, Р.Фәхреддин үзенең 1914 елның 15 ноябрендә чыккан “Шура” журналында басылган “Мөсамәрә” (әңгәмә) дигән күләмле мәкаләсендә бу күренешкә салкын мөнәсәбәт белдереп уза: “Габдулла әфәнде вафат булып җәсәде дәфен ителгәндә, безнең матбугатыбыз галиянга (кайнауга) килде. Дәрде (хәсрәтләнүче) әһелләренең тәэсирләре ташып чыкты, каләмнәр сикертеп-сикертеп чаптылар. Мөхәррирләребез хатирәләр бастырдылар вә Габдулла әфәнде берлә ничек танышканнарын хикәя иттеләр вә үзләре берлә аның арасында мөнәсәбәт булганлыкны аңлаттылар. Өст-өстенә тәрҗемәи хәлләр нәшир кыйлдылар”[12:704]. “Татар шагыйрьләре” басылып чыккач, үз адресына әйтелгән кискен фикерләр, гаепләрне кире кагу максатыннан язылган “Актык

сәлам” мәкаләсенең “Гыйләвә” өлешендә Г.Ибраһимов та Р.Фәхретдин сүзләрендә үзенә таяну нокталары эзли.

Ә инде Әл-Мәдәни шәйх Әбү Сәгыйт “Дин вә мәгыйшәт” журналының 1914 елдагы 18 санында басылган “Шигыр вә шагыйрьләр”[1] мәкаләсендә “Йолдыз” газетасының 966 һәм 967 саннарында шагыйрьне соңгы юлга озату нисбәтле язылган мәкаләдә Тукайга күрсәтелгән олы хөрмәтне шәригать рөхсәт иткән чикләрдән чыгып олылау, зурлау дип кире мөнәсәбәт белдерә.

1913-1914 елларда газета-журнал битләрендә басылган язмаларга килсәк, нәрсәләр әйтергә була. Чыннан да, бу вакытта, аеруча 1913 елның март - май айларында Тукайның вакытсыз үлеменә нисбәтле язмалар бик күп, алар төрле жанрда. Авторлары да - төрле катлау, төрле социаль төркем, сыйныф кешеләре. Бу көннәрдә милләт, халык берләшә. Шагыйрьне югалту ачысы белән яши. Тукай үлеме гомуммилли кайгы буларак кабул ителә. Язмаларның барысы ихлас күңелдән, юксыну, шагыйрьгә тирән мәхәббәт белән сугарылган.

Мәгълүм булганча, Тукай мөселман кагыйдәләренә туры китереп, бөтен йолаларны җиренә җиткереп үтәп, дин-шәригать кануннары нигезендә олы хөрмәт күрсәтелеп, зурлап гүргә иңдерелә. Вакытсыз фани дөньядан мәңгелеккә күчкән шагыйрьнең үлеменә төрле катлам вәкилләре тарафыннан иҗтимагый-милли яссылыкта, дини-фәлсәфи планда, этик-әхлакый, эстетик ноктадан бәя бирелә. Аллаһы Тәгаләнең сыйфатлары турында сөйләгән Коръән-Кәримнең “Шүгәра” сүрәсендә әйтелгән кешенең Аллаһы Тәгалә тарафыннан яратылуы, Раббының кешене дөньядан алуы, Кыямәт көнендә аның яңа баштан Аллаһ хозурына кубарылуы, һәрбер нәрсәгә сәбәпче – Аллаһ кебек дини өйрәтмәләрдән чыгып шагыйрьне югалту кайгысы күңелдән кичерелә. Мәсәлән, “Йолдыз” газетасының 7 апрель санында урнаштырылган тәгъзия телеграммасында болай диелә: “Аллаһы Тәгалә хәзрәтләренә аны дөньядан алу муафикъ булган. Габдулла әфәнденең олугъ сүзләре һәм аның исеме мөкатдәс хәзинә уларак безгә калды. Без аның хәерле варислары уларак аны саклаячакбыз. Аллаһы Тәгалә шундый мөкатдәс һәдияне исраф итүдән мөхафәзә итсен (сакласын), Габдулла әфәнденең урыны җәннәт фирдәвесендә (бакчасында) кыйлсын. Амин!”[10].

Г.Сәгъди, Г.Исхакый язмаларында исә шагыйрьнең үлеме иҗтимагый- милли яссылыкта, ямьсезлек-матурлык, фаҗигалелек эстетик категорияләре аша бәяләнә. Аерым алганда, Г.Исхакый “Милли фаҗига” мәкаләсенең башлам өлешендә шагыйрь, табигатьтән бирелгән сәләт, шагыйрь һәм дөнья, шагыйрь һәм тирәлек, шагыйрь һәм милләт, шагыйрь дигән асыл затның рухи дөньясында мәхәббәт хакындагы әдәби-эстетик, гыйльми карашлары белән уртаклашканнан соң, фикер җебен Тукайга күчерә. Тукайның ятимлектә үсүен, ялгызлыкта гомер итүен, яшәү мәгънәсен, рухи егәрлеген “халыкка хезмәткә, хезмәт эчендә йөзмәк”тә билгеләнгән шагыйрьгә милләт тарафыннан җитәрлек игътибар булмавын, аның тирәлеген, “тәкъдирнең кара кашлы, кара күзле бер кызны аңар йөрәк иптәше итмәвен” шагыйрьне вакытсыз фани дөньядан алып киткән сәбәпләр итеп күрсәтә [7:291]. Тормышны бизәкләндерүче, ямь, җылылык, бирүче нурани мәхәббәт

шагыйрьне фаҗигадән, яшьли үлемнән саклап калучы рухи көч, чара төсендә тәкъдим ителә. Г.Исхакыйның бәя-хөкемнәрендә романтик эстетика сыйфатлары белән культура-тарих мәктәбе кагыйдәләренең синтезы күзәтелә. Ул гына түгел авторның борчылуы, сызлануы чарасызлык, тәкъдир, үлем кебек экзистенциаль мотивлар һәм фаҗига категориясе аша гәүдәләнеш ала. Ә инде матбугатта басылган аерым бәхәсле язмалар уңаеннан дөнья күргән "Тукай мәхәббәте" мәкаләсендә "Тукай безгә кем иде, вә аны хәзер үсәчәк буынга кем иттереп күрсәтергә кирәк?" дигән соравын куя. Исхакый шагыйрь шәхесенең һәм иҗатының кыйммәтен иҗтимагый-милли яссылыкта билгели: "Мәрхүм Тукайның милли кыйммәте аның шагыйрь, милли шагыйрь булуындадыр... .Аның үзенең хосусый тормышында ничек гомер кичергән булуы, нинди даирәдә яшәве киләчәктәге тәнкыйтьчеләр, Тукайның тәрҗемәи хәлчеләре өчен кирәк булса да, бу көнге көндә аларның һичберсенең кирәге - лөзүме юктыр.Ул гына түгел, Тукай хакында аз гына булса да шөбһә уята торган сүзләр сөйләү, төрле уйларга сәбәп була торган мәкаләләр язу – милли тәрбия җәһәтеннән җинаятьтер"[8:314].

Әдәбият галиме Г.Сәгъди "Мохтасар кавагыйде әдәбия" (1912) дигән хезмәтенә Н.Хәлфин, Наразый, Вахидиләрнең рецензияләренә җавап төсендә язган "Әдәби мөзакәрәләр" (1913) авторецензиясендә милли тел – гомуми тел, милли әдәбият – гомуми әдәбият, милли хәят – гомуми тормыш, милләт өчен корбан булу – бәшәрият өчен фида булу кебек фәлсәфи каршылыкларның куйган максатка, яшәү рәвешенә, иҗтимагый-милли тормыштагы урынына карап кеше тарафыннан матур яки ямьсез кабул ителүе турында сүз алып бара. Дини-фәлсәфи, тарих хәрәкәте ноктасыннан караганда, табигатьнең һәм яшәешнең гадәти кануны буларак бәяләнгән халык шагыйре Тукайның үлеме милләтпәрвәрләр өчен ямьсез күренә: "Чөнки бу монда, - дип яза ул, - иң сөекле бер кешебезне югалттык. Бу вакыйга сәбәпле, әдәбият бакчабызда гөл утыртучы бер милли хезмәтчебезне кулдан ычкындырдык. Менә шуңа күрә дә без аның өчен ихтыярсыз кайгырдык вә егладык"[9:329]. Ә башка милләт кешеләре бу вакыйгага артык әһәмият бирмиләр, автор билгеләгәнчә, алар Тукай вафатыннан зыян күрмиләр, шуның өчен шагыйрьнең вакытсыз үлеме башка милләт вәкилләренә ямьсез күренми.

"Вакыт", "Йолдыз", "Кояш" газеталарының 1913 елның апрель саннарында басылган тәгъзияләрдә, тәгъзия-мәкаләләрдә, якын туганнарының, кардәшләренең, гомумән милләтнең тирән кайгысын уртаклашудан тыш, Тукайның иҗатына бәя бирелә, шигъриятенең асыл сыйфатлары аерып чыгарыла, әдәби репутациясе, әдәби әсәрләренең исеменең үлемсезлеге исбатлана.

Иң тәүге тәгъзияләрдә үк Тукай рухи мирасының төп хасиятләреннән берсе – халыкчанлык, халык шагыйре булу ассызыклана. "Вакыт" газетасының 1913 елгы 4 апрель санында урнаштырылган тәгъзиядә шагыйрь иҗатының халыкчанлыгын аңлау омтылышы да ясала: "Ул безнең татар дөньясында иң яшьләй олы шөһрәт тапкан егеттер. Аның бу шөһрәтендә ялган вә фальшелар катнашмаенча, чыннан истихкак (лаек булу) илә булды. Аңа бер дә тышкы тәэсирләр булмаенча, ул халыкның үз арасыннан чыккан, халыкның үз җырын җырлый, шуңа күрә халык

аны бик тиз вә бик яхшы аңлый иде. Әйтергә мөмкин ки, ул халыкның, милләтнең үз шагыйре иде”[4]. Тукай шәхесе халкыбызның гасырлар буена тупланып килгән акыл көче, рухи егәрлеге, бер дәвердән икенче дәвергә күчеп килгән әдәби традицияләр һәм иҗтимагый-милли чынбарлык белән тыгыз бәйләнештә карала: “Милләтебез мондый шагыйрь җитештерү өчен нигә гасырлар тәкямел итәргә һәм дә егерменче гасырның башларындагы кеби фәүкылгадә (гадәттән тыш) тетрәүләрне күреп кичерергә мохтаҗ булды” [4]. Алга таба Тукай шигърияте гомуммилли яссылыкта карала. Иҗтимагый урыны, социаль хәле нинди булуга карамастан, әдип әсәрләренең “халкыбызның һәр сыйныф вә тәбакасендә (катлавында) аңлатып вә сөелеп укылуы”, “аның вакытсыз вафатына һәркем бер тигез кайгыруы” әйтелә.

Шагыйрьнең әдәби репутациясе һәм халык күңелендәге урыны язма авторлары тарафыннан югары стильдә купшы-матур тел белән шартлы-романтик сурәтләр, метафорик образлар ярдәмендә билгеләнә: “Тарих теләсә генә нинди каты ташлардан эшләнсен – гали сарайларны, биек һәйкәлләрне бер көн мәхү (юкка чыгару) вә харап итәр, әмма шагыйрьнең бөтен халкының күкрәгенә нәкыш ителгән “драматизм”нары шул халык яшәдекчә яшәячәктер. Җиһанның Искәндәрләре болар кашында куәтсездер”[10]. Шагыйрьнең рухи дөньясы, каләм көче, сүз куәте дөнья тарихында үз батырлыгы белән дан-шөһрәт казанган, абруй, яхшы ат алган Искәндәр эш гамәленнән өстен куела. Мәкалә авторының Искәндәр исемен телгә алуы очраклы хәл түгел. Аннан соң Тукай фәне өчен әһәмиятле бер фактны искәртик: милли әдәбиятта тарихи теманың сәнгати гәүдәләнешендә бер тенденцияне тәшкил иткән Александр Македонский – Искәндәр шагыйрь шәхесенә һәм иҗатына багышланган язмаларга беренчеләрдән булып килеп керә һәм яңадан күзәтелми. Талантлы, зирәк акылы белән сугыш кырларында, яуларда зур батырлыклар күрсәтеп, үз Ватанын дошманнардан саклап калган бөек полководец Искәндәрнең роле, үз иҗаты каләме белән татар милләтенә хезмәт иткән, аны инкыйраздан саклап, милләтнең “шаһлыгын” күрергә, “тәхетен”, “бәхетен” күрергә хыялланган шагыйрь Тукайга тиңләштереп, алар арасында параллель үткәрелә. Шушы кайгы көннәрендә үк Г.Тукай халык шагыйрь мөнбәренә утыртыла. “Хәзергә кадәр татар галәмендә Габдулла әфәнде кадәр зур урын казанган һичбер шагыйрь булганы юк”[3] рәвешендә Тукайның татар тормышында иҗтимагый-мәдәни рухи дөньясында аерым урыны билгеләнә. Ә күңел җимешләре татар әдәбиятының классикасы дәрәҗәсенә кертелә: “Аның әсәрләре татар әдәбиятының классиклары сәрмаясенә (бәя, дәрәҗә) кичеп мәңге калачагына да шөбһә юктыр” [4].

Алман галиме Михаэл Фридерихның Россиянең үзәк шәһәрләрендәге китапханәләрдә Г.Тукай тормыш юлын һәм әдәби эшчәнлеген яктырткан күп санлы публикацияләрне өйрәнү нәтиҗәсендә “Ein hochgelobter Poet im Dienst von tatarischer Nation und sowjetischen Sozialismus”(1998) дигән хезмәте дөнья күрә. Ул, тарихчы галим И.Гыйлаҗев тарафыннан алман теленнән рус теленә тәрҗемә ителеп, 2011 елда “Габдулла Тукай как объект идеологической борьбы” исемендә

басылып чыкты. Монография хронологик яктан Тукай фәненең 1910 еллардан алып 1980 елларның урталарына кадәр үткән юлын иңли һәм алман ориенталистика мәктәбен үстерүгә үзеннән зур өлеш кертә. Хезмәт Германиядәге “Алман шәрекъ җәмгыяте” галимнәренең югары бәясен ала. Шулай ук татар галимнәре тарафыннан да хуплана. Аерым алганда, тарихчы, тюрколог М.Госманов болай дип яза: “Действительно, монография Михаэла Фридериха, посвященная как жизни, деятельности, творчеству Габдуллы Тукая, так и сложным и спорным проблемам советско-татарского тукаеведения в целом (хронологически со времен самого Тукая почти до наших дней), получилось в подлинном смысле слова фундаментальным исследованием»[12: 5].

Бер мәкаләдә генә әлеге күләмле хезмәтне бәяләү мөмкин түгел (максатыбыз да ул түгел) , шулай да анда, безнең карашыбызча, бәхәсле урыннар бар. Монографиянең “Смерть Габдуллы Тукая”, “Смерть и коммерция” дигән бүлекчәләрендә фәнни эзләнүләребезнең объектына һәм предметына М.Фридерих та игътибарын юнәлтә. ”В центре внимания подавляющего большинства критиков, поэтов и интеллектуалов, писавших о Тукае после его кончины, стояло не качество его литературного творчества. Критики почти исключительно концентрировались на значении , которое имело творчествоТукая для для общественно-политического развития татар. Тукая изображали и представляли общественности как борца против недостатков в современной жизни татар, готовившего почву для лучшего будущего мусульманско-татарской нации.Тогдашние рецензенты, таким образом, привлекали в оценке Тукая тот же критерий, что с середины 1920-х гг. стал господствующим и в Советском Союзе, общественно-политическая актуальность литературы и искусства. Огромная потеря, которой явилась смерть Тукая, была представлена в татарской прессе только в этом нелитературном аспекте”[14:79]. Күренә ки, автор мәсьәләгә Көнбатыш Ауропа гыйльми күзаллавы ноктасыннан якын килә. Дәүләте булмау сәбәпле, телен, динен, мәдәниятен һәм милләтен инкыйраздан саклап калу мәсьәләләре һәрдаим актуальлеген югалтмаган халыкның әдәбияты иҗтимагый-милли, социаль мәсьәләләргә битараф кала алмый. Ул гына түгел, тарихның кискен борылышлары, милләтнең рухи-мәдәни яңарышы вакытында бу аспект беренче планга чыгарга да мөмкин. Әйтергә кирәк, XX гасыр башында шулай була да. Аннан соң бу закончалык гыйльми-нәзари фикер үсеше белән дә раслана. Татар фәнни фикеренең барлыкка килү һәм үсү тарихын тикшергән галимә Д.Заһидуллина нәкъ менә XX гасыр башы татар нәзарият белемендә үзәгенә милләткә хезмәт итү идеясе салынган гыйльми юнәлеш, “җәмгыятьчеләр” мәктәбе формалашуын дәлилли: “Татар нәзари фикере әдәбиятның сурәтләү объекты – татар җәмгыяте, тормыш-чынбарлык күренешләре, ә вазифасы – милләтне үсеш-үзгәрешкә алып бару, файда китерү дип белдерә. Шушы кагыйдәгә нигезләнеп әдәбият концепциясе, әдәби мәктәп формалаша”[5:181]. Ә теоретик фикер, мәгълүм булганча, әдәби практикага, җанлы әдәби процесска, конкрет язучы-шагыйрьләр иҗатына таянып

гомумиләштерүләр ясый. Тукай  бу чорда милли әдәбиятның күтәрелешен, яңарышын тәэмин итүчеләрнең иң алдынгылар сафында бара.

Шигъриятенең тел төзеклеге һәм шомалыгы, вәзен җиңеллеге, мәгънә ачыклыгы, тәгъбир матурлыгы, максат ачыклыгы, камил өслүбе, мотивлар төрлелеге күрсәтелә: “Габдулла Тукаевның шигырьләрендәге ләфызлар (сүзләр) һич тә чуалчык түгел, вәзеннәр җиңел, мәгънәләр ачык, тәгъбирләр матур, максатлар кристалл шикелле ялтырап тора, мөшкил (авыр) мәфһүмнәр дә (эчтәлекләр) аңа җиңеллек илә биреләләр; аның өслүбе аркылы күңелләргә бер дә тәшвишсез (каршылыксыз) рәвештә урынлашып калалар”[4].

Шагыйрьнең үлеменә бер ел тулу уңае белән дөнья күргән мәкаләләр, истәлекләр, хатирәләр Тукайны сагыну, юксыну хисләре белән сугарылган. Уйгур тәхәллүсе астында басылган язмада авторның әдәбият галәмендә хөкем сөргән бушлык, шигърияткә Тукайны алыштырырдай куәтләрнең булмавы, яшь көчләрнең җитешмәве хакындагы бәя-хөкемнәре шагыйрьне юксыну, ачыну хисләре белән үрелеп гәүдәләнә. Ул гына түгел, Тукай үзеннән соңгы шигърияткә бәя бирү бизмәненә, нәзакәт сакчысына әверелә, аның рухи мирасы үрнәгендә шагыйрьләрнең әсәрләре бәяләнә.  Мәкалә 1913-1914  еллар вакылы матбугат сәхифәләрендә дөнья күргән язмаларны иңләп алу максатын куймады һәм ул бер хезмәт кысаларында мөмкин дә түгел.

Күзәтүләрдән чыгып, шуларны әйтергә мөмкин. Г.Тукайның вафаты хәбәре, гәрчә ул Клячкин хастаханәсенең табиблары бәясенә таянып, газета-журналлар битләрендә даими яктыртып барылу сәбәпле көтелмәгән хәл булмаса да, тиз арада бөтен төрки-татар дөньясына таралып, аны авыр һәм тирән кайгыга сала. Шагыйрь белән хушлашу, аерылышу көннәрендә Тукайга моңа кадәр күрелмәгән һәм яңадан кабатланмаячак ихлас күңелдән ихтирам, олылау хисләре һәм бөтен халык мәхәббәте белдерелә. Бу вакыйга милләтнең төрле катламнарын битараф калдырмау сәбәпле, шагыйрьнең үлемен, шәхесен, рухи мирасын дини-фәлсәфи, иҗтимагый-милли, этик-эстетик, гыйльми-нәзари, тәрбияви-әхлакый яссылыкта аңлау һәм бәяләү омтылышы ясала. Жанрлар төрлелеге күзәтелгән язмаларда гасырлар буена шәрехләнәчәк, әдәби бәхәс уятачак, кырыс һәм рәхимсез заманнарда аңа авыр күсәк булып төшәчәк шагыйрь иҗатының халыкчанлыгы, миллилеге, гомуммилли характеры кебек асыл хасиятләре билгеләнә. Һәм әйтергә кирәк, Тукай турындагы гыйлемнең нигез ташларын салуда алар мәгълүм өлеш кертәләр.

**Әдәбият:**


1. Әл-Мәдәни шәйх Әбү Сәгыйт. Шигыр вә шагыйрьләр// Дин вә мәгыйшәт. -  1914. - № 18.
2. Вәлиди Җ. Габдулла Тукай мәҗмугаи әсәре. – Казан: Мәгариф, 1918.
3. Габдулла Тукаев//  Йолдыз. – 1913. – 4 апрель.
4. Габдулла Тукаев// Вакыт. – 1913. – 4 апрель.
5. Заһидуллина Д.Ф. Әдәбият кануннары һәм заман (татар әдбият нәзариясенең барлыкка килүе һәм үсеш баскычлары). - Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. 271 б.
7. Исхакый Г. Милли фаҗига// Гаяз Исхакый. Әсәрләр. Унбиш томда.Т.6. Публицистика һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан:  Татар кит. нәшр., 2005. 288-292б.

8. Исхакый Г. Тукай мәхәббәте// Гаяз Исхакый. Әсәрләр. Унбиш томда.Т.6. Публицистика һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Татар кит. нәшр., 2005.313-317 б.
9. Сәгъди Г. Әдәби мөзакәрәләр// Шура. – 1913. - №11. – 328-332 б.
10 .Тәгъзия // Вакыт. – 1913. – 5 апрель.
11. Тукаевның үлеме мөнәсәбәте илә “Йолдыз” идарәсенә килгән тәгъзия телеграммалары // Йолдыз. - 1913 - 7 апрель.
12. Усманов М.А. Острый взгляд со стороны// Габдулла Тукай как объект идеологической борьбы. – Казан: Татар. кн. изд-во, 2011. - С.3-15.
13. Фәхретдин Р.Мөсамәрә // Шура. - 1914. - №22. – 701-704 б.
14. Фридерих М. Габдулла Тукай как объект идеологической борьбы [пер. с нем. И.А.Гилязова]. – Казань: Татар.кн. изд-во, 2011. – 343с